Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге Советы

КАРАР

«23» октябрь 2024 ел Кече Урыссу ав. №20

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-Фз санлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-Фз санлы Федераль закон, 2013 елның 23 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы»ның 50-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Советының 2023 елның 1 мартындагы 2 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 9.3 нче пунктының 5 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. белем һәм квалификация турында документ;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Ташкичү авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

*Татарстан Республикасы*
*Ютазы муниципаль районы*
*Ташкичү авыл җирлеге башлыгы* *Р.К.Вәлиев*